ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«13» апрель 2020 ел** **№ 295**

**Язгы кыр эшләренә әзерлек һәм аны уздыру чаралары, 2020 елгы язгы кыр эшләрендә катнашучы алдынгы механизаторларны бүләкләү турында**

2020 елгы язгы кыр эшләрен вакытында, оешкан төстә һәм сыйфатлы башкару максатыннан, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәкъдим итәргә:

1.1. Авыл хуҗалыгы оешмалары җитәкчеләренә:

1.1.1. Орлыклык материалны, ашлама һәм авыл хуҗалыгы техникасын әзерләүне, механизатор кадрлар белән комплектацияләүне һәм язгы кыр эшләрен билгеләнгән агротехник срокларда һәм сыйфатлы итеп башкаруны тәэмин итәргә.

1.1.2. Язгы кыр эшләренә җәлеп ителгән хезмәт ресурсларыннан рациональ файдалануны, аларга мәдәни-көнкүреш һәм медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә, югары җитештерүчәнлекле эш өчен шартлар тудырырга, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен төгәл үтәргә.

1.1.3. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә язгы кыр эшләренең барышы турында бюллетеньнәр чыгаруны оештырырга.

1.2. Район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә һәм авыл хуҗалыгы оешмалары җитәкчеләренә:

1.2.1. Язгы кыр эшләрен сыйфатлы һәм оптималь срокларда башкаруны тәэмин итәргә.

1.2. Хуҗалык җитәкчесе тарафыннан эшне дөрес оештырмау сәбәпле ягулык-майлау материаллары булмау, йөк машиналары җитмәү һәм башка сәбәпләр аркасында чәчү агрегатларының, чәчү комплексларының тик торуына юл куймаска.

1.3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча муниципаль районы буенча ЮХИДИ бүлеге, Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенә күчкәндә зур габаритлы авыл хуҗалыгы техникасына машина –трактор паркыннан чыкканда, бер кырдан икенчесенә күчкәндә ярдәм күрсәтергә.

1.4. Арча муниципаль районының массакүләм мәгълүмат чараларына язгы кыр эшләренең барышын һәм комиссия материалларын даими һәм киң

яктырту зарур. Алдынгы хезмәтне пропагандалау һәм хезмәткәрләрне мораль кызыксындыру максатыннан «Мактау тактасы» рубрикасы оештырырга.

1.5. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә, "Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе" төбәк иҗтимагый оешмасының Арча район бүлекчәсенә алдынгы механизаторларны 5-7 көнлек эш нәтиҗәләре буенча матди бүләкләү мөмкинлеген карарга.

3. Расларга:

3.1. Язгы кыр эшләренең барышын оператив җитәкләү өчен язгы кыр эшләрен башкаруның сыйфатын тикшереп тору буенча район комиссиясе составын (1 нче кушымта). Комиссия утырышларында әлеге хуҗалык җитәкчеләре, белгечләре катнашында тикшерү нәтиҗәләре буенча фикер алышырга.

3.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең 2020 елгы язгы кыр эшләрендә катнашучы алдынгы механизаторларын билгеләү буенча район комиссиясе составын (2 нче кушымта).

3.3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең 2020 елгы язгы кыр эшләрендә катнашучы алдынгы механизаторларын бүләкләү турында нигезләмәне (4 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты һәм Арча район Советы аппаратының җаваплы хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең вазыйфаи затларын, республика оешмалары, агросәнәгать комплексы хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы берләшмәләренә язгы кыр эшләрен башкарганда авыл хуҗалыгы товар җитештерүдә гамәли ярдәм күрсәтү өчен беркетергә (3 нче кушымта).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:arsk.tatarstan.ru).

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә. Галимуллин

*Арча муниципаль районы башкарма комитетының*
*«13» апрель 2020 ел, №295*
*карарына 1 нче кушымта*

**Язгы кыр эшләре үткәрүнең сыйфатын тикшереп тору буенча район комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Галимуллин И.Ә. | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Гатиятов Р.М. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча). |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Шакирҗанов Р.Р. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Бәһавиев А.Р. | - РФ Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Мортазин Р.Г. | - "Россельхозцентр» ФДУның Татарстан Республикасы филиалы Арча район бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Касыймов Г.Г. | - Татарстан Республикасы дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Татарстан Республикасы Арча шәһәре һәм Арча муницицыпаль районы бүлеге дәүләт баш инженер-инспекторы (килешү буенча). |
| Әскәров М.Ш. | - Арча муниципаль районы башкарма комитетының хезмәтне саклау буенча белгече. |

*Арча муниципаль районы башкарма комитетының*
*«13» апрель 2020 ел, № 295*
*карарына 2 нче кушымта*

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең 2020 елгы язгы кыр эшләрендә катнашучы алдынгы механизаторларын билгеләү буенча район комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Р.М. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе |
| Абдуллин Л.И. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Абдуллин М.Р. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге башлыгы; |
| Шакирҗанов Р.Р. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге башлыгы; |
| Насыйбуллин И.Р. | - «Татмедиа» ААҖ филиалы, «Арча хәбәрләре» район газетасы редакциясе директоры (килешү буенча); |
| Хәкимҗанов А.Г. | - «Россельхозцентр» ФДУның Татарстан Республикасы филиалы Арча район бүлеге баш агрономы (килешү буенча); |
| Галимова С.П. | - "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы ФБП" МКУ җитәкчесе (килешү буенча); |

*Арча муниципаль районы башкарма комитетының*
*«13» апрель 2020ел, № 295*
*карарына 3 нче кушымта*

**2020 елгы язгы кыр эшләре вакытында эшне оператив оештыру буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы берләшмәләренә гамәли ярдәм күрсәтү өчен җаваплы хезмәткәрләрне беркетү**

| Хуҗалык исеме | Арча район Советы һәм Башкарма комитетының җаваплы затларының ф. и.а.и. | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең вазыйфаи затлары, район оешмалары, АПК хезмәткәрләренең ф.и.а.и. |
|---|---|---|
| “Ташкичү” ҖЧҖ | Нуриев И.Г.– Арча муниципаль районы башлыгы | Хәкимҗанов А.Г. – " Россельхозцентр» ФДУ филиалының район бүлеге баш агрономы (килешү буенча) |
| "Казанка АФ" ҖЧҖ | Касыймов Р.Ф. – Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) | Мифтахов Р.В. – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең ФЭО 3 разрядлы өлкән белгече (килешү буенча) |
| "Курса МТСы" ҖЧҖ | Галимуллин И.Ә.– ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | Абдуллин Л.И. –Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| "Кишет" ҖЧҖ<br>“Кызыл Яр" ҖЧҖ<br>"АФ Аю" ҖЧҖ<br>АФ “Заря " ҖЧҖ<br>“Венета” ҖЧҖ | Гатиятов Р. М. – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы | Мортазин Р.Г. – "Россельхозцентр" ФДУ филиалының район бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| "Игенче АФ" ҖЧҖ<br>“Тукай " ҖЧҖ<br>"Идел” АГРОСӘНӘГАТЬ комплексы” ҖЧҖ | Мөхетдинов Р.Р – - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | Абдуллин М.Р. – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең ФЭО башлыгы (килешү буенча) |
| "Ватан АФ" ҖЧҖ<br>"Северный" АХП ҖЧҖ | Гатиятов Р.М. – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы | Касыймов Г.Г. – Татарстан Республикасы дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Арча шәһәре һәм Арча муниципаль районы бүлеге дәүләт баш инженер-инспекторы (килешү буенча) |
| "Яңарыш АФ" ҖЧҖ | Мөхәммәдияров Р.Д.– ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ башлыгы | Хәйретдинов Р.Р – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе буенча консультанты (килешү буенча) |
| "Ашытбаш АПК" ҖЧҖ<br>“Ашыт” ҖЧҖ | Галимуллин Р.Н. – Арча район Советы аппараты җитәкчесе | Р.А. Фәйзрахманов - «Арча район дәүләт ветеринария берләшмәсе " ДБУ башлыгы (килешү буенча) |
| Сафиуллин КФХ | Игнатов И.И.- ТР Арча МР ПИЗО | Шакирҗанов Р.Р. – Татарстан |

| | | |
|---|---|---|
| "АФ Төрнәле-Пошалым" ҖЧЖ<br>“Сафия ФХ” ҖЧЖ<br>"Нива" «ҖЧЖ | җитәкчесе | Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| "Ак Барс" ҖЧЖ | Нәбиуллин И.М. – -ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы | Абдуллин Л.И. – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| "Кырлай АФ" ҖЧЖ | Мөхәрәмов Р.Р. – ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | Хәйретдинов Р.Р. – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе буенча консультанты (килешү буенча) |

*Арча муниципаль районы*
*башкарма комитетының*
*«13» апреля 2020ел, № 295*
*карарына 4 нче кушымта*

**2020 елгы язгы кыр эшләрендә катнашучы алдынгы механизаторларны бүләкләү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр.**

1.1. Чара авыл хуҗалыгы берләшмәләре хезмәткәрләренең язгы кыр эшләренә әзерлек һәм аны уздырганда игү технологияләрен үтәү һәм яхшы сыйфатлы итеп эшләү югары күрсәткечләргә ирешүдә кызыксынучанлыгын арттыру, максаты белән үткәрелә.

1.2. Ярышта районның 2020 елгы язгы кыр эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы берләшмәләре механизаторлары катнаша.

1.3. Чараны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе оештыра.

1.4. Финанслау Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты хисабына башкарыла. Алдынгы механизаторларны бүләкләүгә акчаларның гомуми күләме 40 мең сум тәшкил итә. Бүләкләнүчеләр саны-20 кеше.

1.5. Конкурсның башлану көне- 2020 елгы язгы кыр эшләре башланганнан соң, әлеге карар Арча муниципаль районының массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан көн.

1.6. Конкурсның тәмамлану көне-2020 елгы язгы кыр эшләре төгәлләнгән көн.

**2. Максат һәм бурычлар.**

2.1. Авыл хуҗалыгы берләшмәләре хезмәткәрләренең язгы кыр эшләрен башкарганда игү технологияләрен үтәп һәм яхшы сыйфат белән югары күрсәткечләргә ирешүдә кызыксынучанлыгын арттыру.

2.2.Хезмәт эшчәнлегендә югары күрсәткечләр өчен матди кызыксындыру.

2.3.Яшь хезмәткәрләрне җәлеп итү өчен авыл хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү.

**3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе.**

3.1. Югары сыйфатлы эшкә ирешкән механизаторлар Арча муниципаль районы башлыгының рәхмәт хаты һәм 2000 шәр сумлык акчалата премияләр белән бүләкләнәләр.

3.2. Алдынгы механизаторларны билгеләгәндә хезмәт һәм технологик дисциплинаның, куркынычсызлык техникасының үтәлеше, башкарылган эшнең сыйфаты, хезмәт җитештерүчәнлегенең югары булуы, физик һәм эталон гектарларда эшкәртү исәпкә алына.

3.3. Нәтиҗәләр атна саен ясала. Җиңүчеләрне бүләкләү хуҗалыкка барып үткәрелә.

3.4. Премия бирүнең нигезе булып авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан 2020 елгы язгы кыр эшләрендә катнашучы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең алдынгы механизаторларын билгеләү буенча район комиссиясенә тапшырылган материаллар тора.

3.5. Конкурста катнашу өчен комиссиягә механизаторларның тракторның маркасын һәм җирне тукландыру, тырмалау, туфрак эшкәртү һәм чәчү эшләренең күләмен күрсәтеп (әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы), җитәкченең имзасы һәм мөһере белән расланган эш күрсәткечләрен бирергә кирәк. Хуҗалык җитәкчесе һәм баш икътисадчы тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук аларны раслый торган документларның дөреслеге өчен закон нигезендә җаваплы.

3.6. Документлар комиссиягә атнага бер тапкыр пәнҗешәмбе көнне бирелә.

3.7. Йомгак ясау комиссия тарафыннан белешмәләр алганнан соң 3 көн эчендә үткәрелә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, конкурс комиссиясе рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

“13” апрель 2020 ел, № 295
*2020 елгы язгы кыр эшләрендә катнашучы алдынгы механизаторларны бүләкләү турындагы нигезләмәгә*
*1 нче кушымта*

2020 елгы язгы кыр эшләре вакытында Арча районы
___________________хуҗалыгының иң яхшы механизаторлары
(________________________торышы буенча)

| Хуҗалык | Механизаторның ф. и. а.и. | Трактор | | Эш төрләре буенча күрсәткечләр, га | | | | Язгы кыр эшләре башланганнан бирле башкарылган эш, га |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Тибы, маркасы | Чыгарылыш елы | агрегатлар кулланып ашлама кертү | Дым каплау | Культи-вация | Барлыгы Чәчү | |
| | | | | | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе ________________ ________________

Баш икътисадчы ________________ ________________